КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 ноябрь г.Казань № 878

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре турында» 2006 ел, 14 август, 414 нче карары белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре турында» 2006 ел, 14 август, 414 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 декабрь, 935 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Созвездие – Йолдызлык» ачык респулика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләр өчен махсус дәүләт стипендияләре түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Махсус стипендияләр кандидатларга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының тиешле финанс елы өчен җыелма сметасында бу максатларга күздә тотылган акча чикләрендә түбәндәге номинацияләр буенча бер тапкыр билгеләнгән тәртиптә түләнә:

«Вокал соло», 1 нче кече төркем (5 – 7 яшь) – һәрберсе 15,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Вокал соло», 2 нче кече төркем (8 – 11 яшь) – һәрберсе 20,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Вокал соло», урта төркем (12 – 15 яшь) кызлар – һәрберсе 20,0 мең сум күләмендә 5 стипендия;

«Вокал соло», урта төркем (12 – 15 яшь) малайлар – 25,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокал соло», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – һәрберсе 25,0 мең сум күләмендә 6 стипендия;

«Вокал соло», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – һәрберсе 35,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Хореография», кече төркем (5 – 11 яшь) – һәрберсе 35,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Хореография», урта төркем (12 – 16 яшь) – һәрберсе 50,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Хореография», өлкән төркем (17 – 21 яшь) – һәрберсе 50,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Хореография», өлкән төркем (17 – 21 яшь) – 40,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокаль ансамбльләр», кече төркем (5 – 11 яшь) – 30,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокаль ансамбльләр», урта төркем (12 – 15 яшь) – һәрберсе 30,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Вокаль ансамбльләр», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – һәрберсе 30,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Конферанс», кече төркем (5 – 9 яшь) – һәрберсе 15,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Конферанс», өлкән төркем (10 – 15 яшь) – 15,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Конферанс», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – 15,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокал соло» номинациясендә фестиваль Гран-прие (5 – 21 яшь) – 70,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Хореография» номинациясендә фестиваль Гран-прие (5 – 21 яшь) – 80,0 мең сум күләмендә 1 стипендия.

«Хореография» һәм «Вокаль ансамбльләр» номинацияләрендә бирелә торган стипендия суммасы тиешле бию коллективында һәм (яки) вокаль коллективта катнашучыларның һәрберсе арасында тигез өлешләргә бүленә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин